МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.08.2014 № 474

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 22 сентябрендә теркәлде, №2433

Социаль реабилитациягә мохтаҗларга
балигъ булмаганнар өчен махсус
учреждениеләргә юллама (путевка)
бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәте күрсәтүне камилләштерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

“Социаль реабилитациягә мохтаҗларга балигъ булмаганнар өчен махсус учреждениеләргә юллама (путевка) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 25 июнь, 2012 ел, №468 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Социаль реабилитациягә мохтаҗларга балигъ булмаганнар өчен махсус учреждениеләргә юллама (путевка) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның җиденче абзацында “ятим балалар һәм балалар мәгариф учреждениеләренең яки башка балалар учреждениеләренең” дигән сүзләрне “ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның” дигән сүзләргә алыштырырга;

1.5 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, тормышта авыр хәлләрдә калган балигъ булмаган сукбай балаларга, яшәү урыны һәм билгеле бер шөгыле булмаган гражданнарга приютта урын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат стандартын раслау турында” 30 июль, 2012 ел, №644 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары

белән расланган Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, тормышта авыр хәлләрдә калган балигъ булмаган сукбай балаларга, яшәү урыны һәм билгеле бер шөгыле булмаган гражданнарга приютта урын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат стандарты нигезендә (алга таба - №644 Сыйфат стандарты) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 03.08.2012, №57, 1975 ст.)";

1 бүлекнең алдагысы кебек үк 1.5 нумерациясенә ия булган соңгы пунктын 1.6 пункт дип исәпләргә;

"Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт" графасына (алга таба – 3 графа) түбәндәге эчтәлектәгеяңа абзац өстәргә:

"№644 Сыйфат стандартының III бүлегенең 1 п.";

Регламентның 3 графасындагы 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"№644 Сыйфат стандартының III бүлегенең 1 п.";

3 графада 2.4 пунктны төшереп калдырырга;

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының (алга таба – 2 графа) 2.5 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Балигъ булмаганның шәхсән гаризасы (балигъ булмаган язу күнекмәләренә ия булмаган очракта, 1нче кушымта нигезендә, балигъ булмаганның шәхсән мөрәҗәгать итүе турында акт)";

2 графаның 2.5 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Балигъ булмаганның ата-аналарын яки башка законлы вәкилләрен тоткарлау, административ арест салу, сак астына алу, кулга алуга хөкем итү, иреген чикләү, иректән мәхрүм итү очракларында башлангыч тикшерү алып баручы затның, тикшерүченең яки судьяның карары.";

3 графасында 2.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"№644 Сыйфат стандартының III бүлегенең 1 п.";

2 графада 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документлар тапшыру таләп ителми.";

3 графада 2.6 пунктның сүзләрен төшереп калдырырга;

3 графада 2.9 пунктны төшереп калдырырга;

"№644 Сыйфат стандартының X бүлегенең 1 п. 1.1 пп.";

Регламентның 2.16 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

"Дәүләт хезмәте күп функцияле үзәкләрдә (алга таба – МФЦ) күрсәтелми.";

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Административ процедуралар составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре”;

3.1 пунктның 3.1.1 пунктчасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан;”;

3.2 пункт атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.”;

3.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Консультацияләр алу өчен бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар күчермәләре, электрон чыганаклардан файдаланып һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин.”;

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасындагы икенче абзацында “почта аша хат белән” дигән сүзләрдән соң “яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон рәвештә” дигән сүзләрне өстәргә;

3.8, 3.9 һәм 3.10 пунктларны 3.5, 3.6 һәм 3.7 пунктлар дип исәпләргә;

3.8 пунктының 3.8.1 һәм 3.8.2 пунктчаларын 3.5 пунктының 3.5.1 һәм 3.5.2 пунктчалары дип исәпләргә.

Регламентның 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге 3.8 пунктны өстәргә:

“3.8. Дәүләт хезмәте МФЦ да күрсәтелми.”;

4 бүлекнең 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән хәл ителә.”;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.9 пунктны өстәргә:

“ Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.”;

Регламентка №1 кушымтада:

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлек) балигъ булмаганның үз ихтыяры белән мөрәҗәгать итүе турында акт формасы” дигән

сүзләрне “ Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлек) балигъ булмаганның шәхсән мөрәҗәгать итүе турында акт формасы” дигән сүзләргә алыштырырга;

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлек) балигъ булмаганның үз ихтыяры белән мөрәҗәгать итүе турында “___”____ 200_ел, №_________ акт” дигән сүзләрне “Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлек) балигъ булмаганның шәхсән мөрәҗәгать итүе турында “___”____ 20_ел, №_________ акт” дигән сүзләргә алыштырырга;

Регламентка 2 нче кушымтада “________дән ________ 200_ елга кадәр ___көнлек срокка вакытлыча яшәүгә кабул итүегезне сорыйм (сорыйбыз) дигән сүзләрне “________дән ________ 20_ елга кадәр ___көнлек срокка вакытлыча яшәүгә кабул итүегезне сорыйм (сорыйбыз) дигән сүзләргә алыштырырга.

**Министр** **А.Р.Шәфигуллин**